КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 27 декабрь г.Казань № 1175

«Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы гран-прие» дигән махсус номинация буенча премия бирү һәм түләү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасындагы фәнни оешмаларда, югары белем бирү мәгариф оешмаларында яки һөнәри белем бирү оешмаларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм Татарстан Республикасында фән үсешенә шактый өлеш кертүчә Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галимнәренә дәүләт ярдәме күрсәтү һәм аларны бүләкләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы гран-прие» дигән махсус номинация буенча премия бирү һәм түләү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 27 декабрь, 1175 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы гран-прие»
дигән махсус номинация буенча премия бирү һәм түләү
тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртиптә Татарстан Республикасының фәнни оешмаларында, югары белем бирү мәгариф оешмаларында яки һөнәри белем бирү оешмаларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган һәм фән үсешенә шактый өлеш керткән Татарстан Республикасы яшь галимнәре өчен «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы гран-прие» дигән махсус номинация буенча премия (алга таба шул ук эзлеклелектә – яшь галимнәр, премия) бирү һәм түләү максатлары, тәртибе һәм шартлары билгеләнә.

2. Премия бирүнең максаты – яшь галимнәрне бүләкләү.

Премия бирү бурычлары:

Татарстан Республикасында яшьләр арасында фәнни-тикшеренү эшчәнлеген популярлаштыру һәм стимуллаштыру;

фәнни һәм инновацион өлкәләрдә Татарстан Республикасының кадрлар потенциалын үстерү;

Татарстан Республикасында яшьләр арасында фәнни, фәнни-педагогик һәм фәнни-техник хезмәткәр һөнәренең абруен күтәрү.

3. Әлеге Тәртип максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

яшь галим – Татарстан Республикасының фәнни оешмаларында, югары белем бирү мәгариф оешмаларында яки һөнәри белем бирү оешмаларында фәнни, фәнни-педагогик яки фәнни-техник хезмәткәр вазыйфасында кимендә биш ел хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган, фәннәр кандидаты яки фәннәр докторы дигән гыйльми дәрәҗәсе булган, конкурска гариза (алга таба – гариза) бирү датасына 35 яшьтән (фәннәр кандидатлары өчен) яки 40 яшьтән (фәннәр докторлары өчен) артмаган, фән үсешенә шактый өлеш керткән Россия Федерациясе гражданы;

конкурс – яшь галимнәр өчен «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы гран-прие» дигән махсус номинациядә катнашучылар арасыннан премия лауреатларын сайлап алу максатларында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан үткәрелә торган чара;

конкурста катнашучы – конкурска гариза биргән һәм әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган яшь галим;

конкурс комиссиясе – конкурста җиңүчеләрне – премия лауреатларын билгеләү максатларында төзелә торган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршындагы комиссия;

премия – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан премия лауреатларына түләүсез бирелә торган акча;

премия лауреатлары – «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы гран-прие» дигән махсус номинациядә җиңүчеләр дип танылган конкурста катнашучылар.

4. Премия түләү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5. Премия лауреатларына түбәндәге күләмдә премия бирелә:

I дәрәҗә гран-при – 500 мең сум;

II дәрәҗә гран-при – 350 мең сум;

III дәрәҗә гран-при – 250 мең сум.

6. Конкурс ел саен елына бер тапкыр үткәрелә.

## II. Конкурста катнашучыларга карата таләпләр

7. Гариза бирү көненә түбәндәге таләпләргә туры килә торган яшь галимнәргә конкурста катнашырга рөхсәт ителә:

а) экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

б) БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

в) «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

г) аларга карата Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә банкротлык процедурасы билгеләнмәгән;

ж) бердәм салым счетында яшь галим тарафыннан конкурста катнашуга гариза бирелгән айның 1енче көненә Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычы юк;

е) фәнни оешмаларда, югары белем бирү мәгариф оешмаларында яки һөнәри белем бирү оешмаларында тулы эш белән тәэмин итү шартларында төп эш урыны буенча фәнни, фәнни-педагогик яки фәнни-техник хезмәткәр вазыйфасында хезмәт эшчәнлеген кимендә биш ел гамәлгә ашыра;

ж) фәнни казанышлары һәм Татарстан Республикасы фәнен үстерүгә керткән шәхси өлеше бар;

з) гариза бирү көненә конкурста катнашучыларның иң чик яше түбәндәгечә тәшкил итә:

фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия катнашучылар өчен – иң күбе 35 яшь (35 яшьне кертеп);

фәннәр докторы дигән гыйльми дәрәҗәгә ия катнашучылар өчен – иң күбе 40 яшь (40 яшьне кертеп).

## III. Конкурс үткәрү тәртибе

8. Конкурс үткәрү турында карар Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан кабул ителә һәм боерык белән рәсмиләштерелә.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы конкурс үткәрү турында боерык расланган көннән алып өч эш көне эчендә конкурс үткәрү турында белдерүне үзенең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – сайт) урнаштыру юлы белән конкурс үткәрү турында мәгълүматның ачык булуын тәэмин итә.

9. Конкурс үткәрү турында белдерү түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

а) Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

б) конкурс үткәрү сроклары (гаризалар кабул ителә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы һәм вакыты, конкурс нәтиҗәләрен игълан итү датасы, конкурс үткәрү датасы);

в) әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган яшь галимгә карата таләпләр һәм яшь галимнәр тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге;

г) гаризалар бирү тәртибе һәм аларга һәм теркәлә торган әлеге Тәртипнең 10 – 13 пунктларында каралган документларга карата куела торган таләпләр;

д) премия лауреаты премия бирү турында шартнамәгә имза куярга тиешле срок;

е) премия күчерү шартлары, тәртибе һәм сроклары.

10. Конкурста катнашу өчен яшь галимнәр конкурс үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срок эчендә әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча гариза тапшыра, анда аларның әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган таләпләргә туры килүе һәм әлеге Тәртипнең 24 пунктында каралган премия бирү шартлары белән риза булуы турында тамга куела, гаризага түбәндәге документлар (алга таба – конкурста катнашу өчен документлар) теркәлә:

а) гражданның шәхесен таныклый торган документ күчермәсе;

б) тиешле рәвештә расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясы белән билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар;

в) яшь галимнең эш урыныннан гариза бирү датасына кадәр 15 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән, яшь галим фәнни, фәнни-педагогик яисә фәнни-техник хезмәткәр вазыйфасында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган фәнни оешма, югары белем бирү мәгариф оешмасы яисә һөнәри белем бирү оешмасы реквизитлары күрсәтелгән, вазыйфа һәм әлеге вазыйфада эш стажы турында белешмәне үз эченә алган, кәгазь чыганакта фәнни оешма, югары белем бирү мәгариф оешмасы яки һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесе яки аның урынбасары тарафыннан имзаланган һәм мөһер белән таныкланган белешмә кәгазе;

г) салым түләүченең идентификация номерын бирү турында таныклык күчермәсе, яисә салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе, яисә салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән

салым органында исәпкә кую турында хәбәрнамә күчермәсе;

д) тиешле рәвештә таныкланган, гыйльми дәрәҗә булуны раслый торган документ күчермәсе;

е) яшь галим турында белешмәләр: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), эш урыны, били торган вазыйфасы, гыйльми дәрәҗәсе (булганда), туган көне, өй һәм хезмәт адресы, өй, хезмәт телефоннары номерлары, электрон почта адресы, яшь галим катнашында бастырып чыгарылган фәнни эшләр, монографияләр, фәнни конференцияләрдә чыгышлар исемлеге, яшь галим катнашында алынган грантлар, премияләр саны һәм исеме;

ж) яшь галимнең бердәм салым счетында яшь галим тарафыннан конкурста катнашуга гариза бирелгән айның 1енче көненә Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычы булмавы турында салым органының белешмә кәгазе;

з) яшь галим тарафыннан фәнни, фәнни-педагогик яки фәнни-техник хезмәткәр вазыйфасында хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган фәнни оешма, югары белем бирү мәгариф оешмасы яки һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесе имза куйган, яшь галимнең фәнни казанышлары һәм Татарстан Республикасы фәнен үстерүгә керткән шәхси өлеше турында белешмә бирелгән, ирекле рәвештә язылган хат-үтенечнамә. Хат-үтенечнамәгә, булган очракта, яшь галим премия алуга тәкъдим ителә торган, басылып чыккан яисә башка ысул белән халыкка җиткерелгән фәнни тикшеренүләр яки эшләнмәләр теркәлә;

и) Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Фәнни оешмаларның һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының яшь галимнәренең фәнни эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү методикасынраслау турында» 2023 елның 11 сентябрендәге 887 номерлы боерыгы нигезендә исәпләнгән һәм рәсмиләштерелгән, яшь галим тарафыннан фәнни, фәнни-педагогик яки фәнни-техник хезмәткәр вазыйфасында хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган фәнни оешма, югары белем бирү мәгариф оешмасы яки һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесе раслаган фәнни эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү исәп-хисабы;

к) «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә яшь галимнең ризалыгы;

л) яшь галимнең индивидуаль шәхси счетының иминият номерыннан белешмә;

м) яшь галимнең банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счеты реквизитлары бирелгән документ.

11. Конкурста катнашу өчен документларны кабул итү конкурс үткәрү турында белдерү сайтта урнаштырылган көннән алып 20 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

12. Конкурс өчен гариза һәм аңа теркәлә торган документлар конкурста катнашу өчен түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә тапшырыла.

13. Конкурста катнашу өчен документлар рус телендә бер нөсхәдә кәгазь рәвешендә һәм электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларында рәсмиләштерелә һәм 420021, Казан шәһәре, Сафьян урамы, 5 нче йорт адресы буенча һәм «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме конкурсының гран-прие» дигән махсус номинация премиясе конкурсына» тамгасы белән mdmrt@tatar.ru электрон почта

адресына җибәрелә.

14. Конкурста катнашу өчен документларны теркәү конкурс комиссиясенең җаваплы сәркәтибе тарафыннан, аларның керү тәртибен һәм вакытын күрсәтеп, алар кергән вакытта башкарыла. Әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән кабул итү срогы тәмамланган көннән алып, конкурста катнашуга җибәрелгән документлар теркәлми һәм каралмый. Конкурста катнашу документларына өстәмәләр кертү һәм (яки) алыштыру әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән кабул итү срогы тәмамланганга кадәр башкарылырга мөмкин, шул ук вакытта әлеге документларга яңа теркәү номеры бирелми, алар элек җибәрелгән конкурста катнашу документларына теркәлә.

15. Яшь галимнәргә конкурста катнашырга рөхсәт итү һәм алга таба аларны конкурс комиссиясе утырышында карау өчен яшь галимнәрнең әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә, шулай ук яшь галим тарафыннан конкурста катнашырга тапшырылган документларның тулы комплектта булуын һәм әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү конкурс комиссиясенең җаваплы сәркатибе тарафыннан документларны бирү срогы тәмамланган көннән алып 15 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

16. Яшь галимгә конкурста катнашырга рөхсәт итмәү өчен нигезләр:

а) конкурста катнашу өчен документларны тапшырмау яки тулы комплектта тапшырмау;

б) конкурста катнашу өчен тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавын ачыклау;

в) яшь галим әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү.

17. Конкурс комиссиясенең җаваплы сәркәтибе, әлеге Тәртипнең 15 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 2 кушымтасында бирелгән форма нигезендә конкурста катнашучылар исемлеген төзи һәм аны конкурс комиссиясенә конкурста катнашучыларның документлары белән бергә тапшыра.

Яшь галимгә конкурста катнашырга рөхсәт итмәү өчен нигезләр булган очракта, җаваплы сәркәтип исемлекләрне төзегән һәм тапшырган көннән алып биш эш көне эчендә яшь галимгә, конкурста катнашырга рөхсәт итмәү сәбәпләрен күрсәтеп, хәбәрнамә җибәрә.

18. Конкурс комиссиясенең сан һәм шәхси составы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы боерыгы белән билгеләнә һәм раслана.

Конкурс комиссиясе түбәндәге составта төзелә: рәис, рәис урынбасарлары, җаваплы сәркәтип һәм әгъзалар.

Конкурс үткәрү эшчәнлеге конкурс комиссиясе тарафыннан түләүсез нигездә башкарыла.

19. Конкурс комиссиясе катнашучылар исемлеген алган көннән 30 эш көненнән дә соңга калмыйча:

Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Фәнни оешмалардагы һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларындагы яшь галимнәрнең фәнни эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү методикасын раслау турында» 2023 елның 11 сентябрендәге 887 номерлы боерыгы белән расланган Фәнни оешмалардагы һәм

югары белем бирү мәгариф оешмаларындагы яшь галимнәрнең фәнни эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү методикасы буенча исәпләп чыгарылган фәнни эшчәнлек нәтиҗәлелегенең йомгаклау билгесе кимү буенча конкурста катнашучыларны рангларга бүлүне гамәлгә ашыра;

рангларга бүлү нәтиҗәләре буенча иң югары баллар җыйган өч премия лауреатын билгели (берничә катнашучы бер үк күләмдә баллар җыйган очракта, лауреат итеп документлары беренче булып кергән катнашучы билгеләнә);

карар белән лауреатлар исемлеген раслый.

20. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр конкурс комиссиясе әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

Конкурс комиссиясе утырышында конкурс комиссиясе рәисе булмаган очракта, аның вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе карары белән билгеләнгән конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе карары, конкурс комиссиясе утырышында катнашучылар тарафыннан гади күпчелек тавыш бирелгән очракта, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисенең яки конкурс комиссиясе рәисе урынбасарының (конкурс комиссиясе рәисе булмаганда) тавышы хәлиткеч булып тора.

Конкурс комиссиясе карары конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә, аңа, кабул ителгән көненнән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, конкурс комиссиясе рәисе яки конкурс комиссиясе рәисе урынбасары (конкурс комиссиясе рәисе булмаганда) тарафыннан имзалана. Карар ахыргы булып тора һәм яңадан каралырга тиеш түгел. Конкурс йомгаклары буенча апелляция каралмаган.

21. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат, конкурс комиссиясе тарафыннан карар кабул ителгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, конкурста катнашучыларга https://minmol.tatarstan.ru/konkurs-luchshiy-molodoy-ucheniy-respubliki.htm сайтында премия лауреатлары исемлеген урнаштыру юлы белән җиткерелә.

## IV. Премия түләү шартлары һәм тәртибе

22. Әлеге Тәртипнең 20 пункты нигезендә рәсмиләштерелгән комиссия утырышы беркетмәсе, комиссия утырышы беркетмәсенә имза куелган көннән алып җиде эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының премия түләү турында боерыгын әзерләү һәм раслау өчен нигез булып тора.

23. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы боерыгы премия лауреатларына премия түләү өчен нигез булып тора.

24. Премия, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының премия түләү турында боерыгы чыгарылган көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, премия лауреатына аның шәхси счетына акчасыз формада күчерелә.

## V. Йомгаклау нигезләмәләре

25. Конкурста катнашу өчен гариза һәм аңа теркәлә торган документлар Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан биш ел дәвамында саклана.

26. Конкурс үткәрү шартлары һәм тәртибе үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

«Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы гран-прие» дигән махсус номинация буенча премия бирү һәм түләү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы гран-прие»
дигән махсус номинация буенча конкурста катнашуга
гариза

| | |
|---|---|
| 1. Гариза бирүче эшли торган оешма (юридик затның тулы һәм кыскартылган исемен, адресын күрсәтергә): | |
| 2. Оешма җитәкчесе: | |
| фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | |
| вазыйфасы | |
| эш телефоны | |
| 3. Гариза бирүче: | |
| фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | |
| туган көне | |
| вазыйфасы | |
| телефоны | |
| электрон почта | |
| 4. Фәнни эш турында мәгълүмат: | |
| исеме | |
| 5. Фәнни эшнең тасвирламасы (Татарстан Республикасы өчен фәннең перспектив өлкәләрен үстерү өчен эшнең әһәмиятлеге һәм актуальлеге нигезләмәсе, аның төп бүлекләре эчтәлегенең кыскача тасвирламасы, тасвирнамәләре һ.б., аны башкару нәтиҗәсендә ирешелгән нәтиҗә) | |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы гран-прие» дигән махсус номинация буенча премия бирү һәм түләү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 27 декабрь, 1175 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы гран-прие» дигән махсус номинация буенча премия бирү һәм түләү тәртибенең 10 пункты нигезендә гаризага түбәндәге документларны терким:

а) гражданның шәхесен таныклый торган документ күчермәсе;

б) тиешле рәвештә расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66[1] статьясы белән билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар;

в) яшь галимнең эш урыныннан гариза бирү датасына кадәр 15 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән, яшь галим фәнни, фәнни-педагогик яисә фәнни-техник хезмәткәр вазыйфасында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган фәнни оешма, югары белем бирү мәгариф оешмасы яисә һөнәри белем бирү оешмасы реквизитлары күрсәтелгән, вазыйфа һәм әлеге вазыйфада эш стажы турында белешмәне үз эченә алган, кәгазь чыганакта фәнни оешма, югары белем бирү мәгариф оешмасы яки һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесе яки аның урынбасары тарафыннан имзаланган һәм мөһер белән таныкланган белешмә кәгазе;

г) салым түләүченең идентификация номерын бирү турында таныклык күчермәсе, яисә салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе, яисә салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән салым органында исәпкә кую турында хәбәрнамә күчермәсе;

д) тиешле рәвештә таныкланган, гыйльми дәрәҗә булуны раслый торган документ күчермәсе;

е) яшь галим турында белешмәләр: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), эш урыны, били торган вазыйфасы, гыйльми дәрәҗәсе (булганда), туган көне, өй һәм хезмәт адресы, өй, хезмәт телефоннары номерлары, электрон почта адресы, яшь галим катнашында бастырып чыгарылган фәнни эшләр, монографияләр, фәнни конференцияләрдә чыгышлар исемлеге, яшь галим катнашында алынган грантлар, премияләр саны һәм исеме;

ж) яшь галимнең бердәм салым счетында яшь галим тарафыннан конкурста катнашуга гариза бирелгән айның 1енче көненә Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычы булмавы турында салым органының белешмә кәгазе;

з) яшь галим тарафыннан фәнни, фәнни-педагогик яки фәнни-техник хезмәткәр вазыйфасында хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган фәнни оешма, югары белем бирү мәгариф оешмасы яки һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесе имза куйган, яшь галимнең фәнни казанышлары һәм Татарстан Республикасы фәнен үстерүгә керткән шәхси өлеше турында белешмә бирелгән, ирекле рәвештә язылган хат-үтенечнамә. Хат-үтенечнамәгә, булган очракта, яшь галим премия алуга тәкъдим ителә торган, басылып чыккан яисә башка ысул белән халыкка җиткерелгән фәнни тикшеренүләр яки эшләнмәләр теркәлә;

и) Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Фәнни оешмаларның һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының яшь галимнәренең фәнни эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү методикасын раслау турында» 2023 елның 11 сентябрендәге 887 номерлы боерыгы нигезендә исәпләнгән һәм рәсмиләштерелгән, яшь галим тарафыннан фәнни, фәнни-педагогик яки фәнни-техник хезмәткәр вазыйфасында хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган фәнни оешма, югары белем бирү мәгариф оешмасы яки һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесе раслаган фәнни эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү исәп-хисабы;

к) «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә яшь галимнең ризалыгы;

л) яшь галимнең индивидуаль шәхси счетының иминият номерыннан белешмә;

м) яшь галимнең банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счеты реквизитлары бирелгән документ.

20___ ел, «___» ___________ _______________ ____________________

(имза) (имзаны таркатып язу)

«Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы гран-прие» дигән махсус номинация буенча премия бирү һәм түләү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

## «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» конкурсы гран-прие» дигән махсус номинация буенча премия бирүгә дәгъва итүче катнашучылар исемлеге

| Т/с | Катнашучы турында белешмәләр | | | | | | | | | Конкурста катнашучының хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган оешма исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) | шәхесне раслый торган документ | | | туган көне, ае, елы | гыйльми дәрәҗәсе[1] | фәнни эшчәнлек нәтиҗәлелеге күрсәткечләре[2] | фән өлкәсендә белгечлек исеме[3] | эш стажы[4] | |
| | | сериясе һәм номеры | бирү датасы | кем биргән | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| | | | | | | | | | | |

Конкурс комиссиясенең җаваплы сәркатибе ________________________________________ ____________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имзасы)

---

[1]«Фәннәр кандидаты» яки «фәннәр докторы» дип күрсәтелә.

[2]Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Фәнни оешмалардагы һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларындагы яшь галимнәрнең фәнни эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү методикасын раслау турында» 2023 елның 11 сентябрендәге 887 номерлы боерыгы белән расланган Фәнни оешмалардагы һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларындагы яшь галимнәрнең фәнни эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү методикасы нигезендә яшь галимгә исәпләнгән баллар саны күрсәтелә.

[3]Табигый фәннәр, техник фәннәр, медицина фәннәре, авыл хуҗалыгы фәннәре, социаль һәм гуманитар фәннәр кебек өлкәләрнең берсендә яшь галимнең специализациясе күрсәтелә.

[4]Фәнни, фәнни-педагогик яки фәнни-техник хезмәткәр вазыйфасында эш стажының елы һәм айлары тулысынча күрсәтелә.

____________________________